| | | |
|---|---|---|
| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |

ПРИКАЗ БОЕРЫК

___14.12.2022__ Казан шә һ ә ре № __139_

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 июнендәге 37 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актын федераль законнарга яраштыру максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 июнендәге 37 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 27.05.2020 № 55, 07.10.2020 № 101 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның түләттерүгә ышанычсыз булуын тану турында карарлар кабул итү тәртибендә:

2 пунктта:

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда һәм, «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд

пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча әҗәт өлешендә. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә ала торган органның юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлдә түгел дип танылган очракта, әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләттерү өчен ышанычсыз дип танылган бюджет түләүләре буенча әҗәт бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш.»;

7 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пунктын өстәргә:

«$2^1$. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен ышанычсыз дип танылa.»;

3 пунктта:

1 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

4 пунктчада:

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юридик зат – бюджетка түләүләр түләүчене теркәүче орган карары буенча әлеге реестрдан төшереп калдыру турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ; «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару эшчәнлеген тәмамлау турында карар.»;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең $2^1$ пунктында каралган нигезләр булганда:»;

7 пунктта «финанс-икътисадый контроль бүлеге» сүзләрен «финанс-икътисад бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «4, 5, 6 пунктларда» сүзләрен «5, 6 пунктларда» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Комиссия утырышында аның барлык әгъзалары да катнашса, Комиссия карары тулы хокуклы дип санала.

Комиссияне Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли.

Комиссия карарны комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул итә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүче затның тавышы хәлиткеч булып тора.

Инспекциянең структур бүлекчәләреннән кергән көннән алып җиде календарь көннән дә соңга калмыйча документларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танырга;

б) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танудан баш тартырга. Әлеге карар Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне кабат карауга комачауламый.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында бәяләмә Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана һәм түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

а) оешманың тулысынча аталышы (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме);

б) салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик затның салым түләүчесенең идентификацияләү номеры) (булган очракта);

в) бурычны барлыкка китергән түләү турында белешмәләр;

г) шуның буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәрен классификацияләү коды, аның атамасы;

д) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычның суммасы;

е) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә ышаныч юклыгын тану турында карар кабул ителү көне;

з) Комиссия әгъзаларының имзалары.»;

13 пунктта «Комиссия карары» сүзләрен «Бәяләмә» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «Комиссия карары» сүзләрен «Бәяләмә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган бюджет керемнәренең баш администраторы (администратор) буларак Инспекция хисабыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләрне түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында өземтә формасында «Финанс-икътисадый контроль бүлеге башлыгы урынбасары» сүзләрен «Финанс-икътисад бүлеге башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган банкротлык турындагы эш буенча эш кузгату өчен нигезләр булмавы турында белешмә формасында «Хокук идарәсе» сүзләрен «Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенең хокук бүлегенә

әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов